**“Туган ягым – яшел бишек” повестеннән өзек.** Сабантуй турындагы өзекнең эчтәлеге. Сабантуй бәйрәменең тасвирлап бирелеше. Көрәшче егетләр, Хәкимҗан образлары. Сурәтләү чаралары. Сабантуй бәйрәме тарихы (*3 сәгать*).
**Лотфулла Фәттахов.**
Рәссамның тормышы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат. “Сабантуй” картинасында сурәтләнгән табигать, авыл кешеләре (*1 сәгать*).
**Балалар өчен чыга торган газета-журналлар.**
**“Сабантуй” журналы.** Журнал басылып чыгу тарихы. Журнал рубрикалары. Мәкаләләрнең эчтәлеге *( 2 сәгать).*

**7 класс**

**I бүлек Халык хаклы.Народ правдив**

**Халык авыз иҗаты. Йола фольклоры.** Йола фольклоры турында төшенчә. Йолаларның төрләре. Алар – халыкның рухи байлыгы, халыкны милләт итеп берләштерә торган асыл нигезләрнең берсе. Аларның көнкүреш һәм дини гореф-гадәтләр белән бәйләнеше, төрләре, үзенчәлекләре .

**Гаилә йолалары.** “Бәби туе”, “Туй” йолалары турында белешмә. Аларны үткәрү тәртибе .
**Халык авыз иҗаты. Бәетләр.** Бәетләрнең лиро-эпик жанр булуы. “Сак-Сок” бәете. Кошларга әйләнгән ике бала язмышының фаҗигасе, бәетнең фантастик сюжетка корылган булуы .
**Мөнәҗәтләр.** Мөнәҗәтләрнең лирик жанр булуы, аларның нигезендә ялгызлыкта үз-үзең белән сөйләшү, Илаһи көчкә мөрәҗәгать итү, ялварып, ярлыкауны сорау икәнлеге турында мәгълүмат. Мөнәҗәтләрнең борынгы заманнардан ук татар язма әдәбиятының һәм халык иҗатының үзенчәлекле жанры булып формалашуы. “Туган ил исемнән китмәс” мөнәҗәтендә туган ил темасының бирелеше .
**Габдулла Тукай.** Шагыйрь иҗаты турында белешмә. “Милли моңнар” шигыре. Шагыйрь һәм милләт язмышы мәсьәләсе .
Повторение ранее изученных жанров фольклора. Работа со схемой. Народная жизнь и быт в обрядовом фольклоре. Семейные (рождение ребёнка, свадьба и др.) и календарные обряды. Трансформация обрядов в письменной литературе (Ф. Бурнаш «Яшь йөрәкләр» / «Молодые сердца» (драма). Баиты, их поэтические особенности («Сак-Сок»/ «Сак-Сук»), мунаджаты («Илемне онытмам» / «Не забуду Родину»). Отражение фольклорных мотивов в творчестве Г.Тукая («Милли моңнар» / «Национальные напевы» Проект о Г.Тукае «Творчество поэта»
**2.Аксакаллар сүзе.Слово мудрецов.**

**Фатих Әмирхан.** Тормышы һәм иҗади эшчәнлеге. “Ай өстендә Зөһрә кыз” әсәренең татар халык әкиятләренә нигезләнүе. Яхшылык белән явызлык көрәше.

Әдәбият теориясе. Әдәбиятта фольклоризм.

**Галимҗан Ибраһимов .** Язучының тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Алмачуар” хикәясе. Хайваннарга карата миһербанлылык хисләре тәрбияләү .

**Татар халкының милли киемнәре һәм бизәнү әйберләре .** Түбәтәй (кәләпүш), калфак, читек,чулпы, беләзек, изү турында мәгълүмат. Милли киемнәрнең үзенчәлеге, вакыт узган саен үзгәрүләргә бирелүе, халкыбыз үткән зур тормыш юлын, аның үткәнен һәм бүгенгесен чагылдыруы .

**Рөстәм Яхин.** Композиторның тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Аның профессиональ җырлар, романслар, музыкаль әсәрләр башкаруындагы эшчәнлеге. Рөстәм Яхин – Татарстан Республикасының Дәүләт гимны авторы .

**Халисә Мөдәррисова.** Шагыйрәнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Көмеш дага” шигырендә бәхет төшенчәсенең тирән фәлсәфәсен ачуы. Сугыш фаҗигасенең чагылышы .

Творчество Ф. Амирхана. Связь татарской литературы с фольклором и мифологией. Ф.Амирхан «Ай өстендә Зөһрә кыз» / «Зухра на Луне». Система образов в сказке, символические образы. Авторский комментарий происходящих событий.

Творчество Г. Ибрагимова. Изображение народной жизни («Алмачуар» / «Чубарый»). Система образов в произведении, образ Алмачуара. Любовь Закира к лошади.Национальная одежда, предметы обихода. Р.Миннуллин «Килен төшкәндә» /«Встреча невесты».

Деятельность композитора Р. Яхина.Изучение стихотворения Х. Мударрисовой «Көмеш дага» / «Серебряная подкова»

**3.Ил язмышы ынанычлы кулларда.Судьба страны в надёжных руках.**

**Әдип Маликов.** Шагыйрь турында белешмә. «Ил язмышы — ир язмышы” шигырендә ватанпәрвәрлек билгеләре чагылу. Шигырьдә оптимистик рух.

Әдәбият теориясе. Гражданлык лирикасы. Пафос .

**Гадел Кутуй.** Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Сагыну” нәсере. Сугыштагы кешенең кичерешләрендә туган ил образы.

Әдәбият теориясе. Нәсер турында төшенчә. Инверсия.

**Сибгат Хәким.** Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Бакчачылар” поэмасы, “Бу кырлар, бу үзәннәрдә” шигыре. Әсәрләрдә лиризм, сәнгатьчә гадилек һәм осталык, ватанпәрвәрлек хисләре чагылышы .

**Хәсән Туфан.** Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Агыла да болыт агыла”, “Тамчылар ни диләр?” шигырьләре. Чор белән бәйле шәхес фаҗигасе, хаксызга рәнҗетелгән кешеләр язмышы ..

**Һади Такташ.** Тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Алсу” поэмасы. Яшәү шатлыгы, оптимизм, үзеңне бәхетле тою хисләре чагылышы.

Әдәбият теориясе. Рефрен, кабатлау .

Ознакомление со стихотворением «Ил язмышы – ир язмышы» /«Судьба родины – судьба мужчины» А.Маликова, стихотворением в прозе «Сагыну» / «Тоска» Г. Кутуя.Жизнь и творчество С. Хакима. Поэма «Бакчачылар» / «Садоводы». Изображение жизни тыла в военное время. Стихотворение «Бу кырлар, бу үзәннәрдә…» / «В этих полях, долинах…» С.Хакима. Образ родного края,мифологизация образа родины. Определение фольклорной традиции в произведениях С. Хакима,художественных функций фольклорных мотивов, образов, поэтических средств в литературном произведении.Особенности лирического рода; образ лирического героя, его чувства-переживания.

**4. Заман герое.Герой своего времени.**

Н.Думавиның иҗаты.”Беренче кар” шигырендә табигать күренешен тасвирлау.Һади Такташның тормыш юлы, иҗаты.”Алсу “ поэмасының шигъри үзенчәлекләре, кабатлаулар. Поэмада рефрена күренеше.Х.Туфанның тормыш һәм иҗат юлы. “Агыла да болыт агыла” шигыре.

Х.Туфанның Аксубай районындагы музее.Г.Тавлин “Кояш болытка кергәндә” романынна өзек белән танышу. Әсәрдәге вакыйгалар аша шәхес культы фаҗигасен ачу. Кабатлау. Тест.
Творчество Назипа Думави. Изображение пейзажа в стихотворении «Беренче кар» /«Первый снег».Жизнь и творчество Хади Такташа. Поэтические особенности поэмы «Алсу». Приемы повторений, рефренов в поэме.Жизненный и творческий путь Хасана Туфана. «Агыла да болыт агыла»/ «Плывут и плывут облака»,«Тамчылар ни диләр?» / «О чём рассказывают капли?».
Дом-музей Х. Туфана в родной деревне Старокарметово Аксубаевского района РТ.Гурий Тавлин. «Кояш болытка кергәндә»/ «Когда тучи заслоняют солнце».

**5. Туган ил темасы. Тема Родины.**

**А.Гыйләҗевнең** тормыш юлы, иҗат юлы. Татар әдәбиятының милли сәнгать традицияләренә әйләнеп кайтуы. “Өч аршин җир” повесты белән танышу. Туган җиреннән ерак булган кешенең сәнгатьчә фикер йөртү юллары. И. Юзеевның тормыш юлы һәм иҗаты.“Ак калфакны төшердем кулдан “ исемле драма әсәре.Әсәрдә социаль –этик проблемалар. Кешене чит илдә тасвирлау. Автор ремаркалары.Образлар,символлар. Ф.Сафин иҗаты.”Туган җиремә” шигырен өйрәнү.Туган җиргә, туган табигатькә, тирә-юньне булган мөнәсәбәтне сәнгатьчә ачуга багышланган лирик әсәр. М.Галеев иҗаты. “Нигез” повестеннән өзек белән танышу. Әсәрдә сугыш чоры вакытының авырлыкларын сүрәтләү. Геройларга хас булган әдәплелек, үз-үзеңә ышану хисләренең чагылышы. Авторның образлар аша фикер йөртүе.
Жизненный и творческий путь А.Гилязева. Возвращение татарской литературы к национальным художественным традициям: повесть «Өч аршын җир»/ «Три аршина земли» (отрывок). Художественное осмысление национальных черт характера человека, находящегося вдали от Родины. Жизнь и творчество И. Юзеева. Драматическое произведение «Ак калфагым төшердем кулдан» /«Выронили белый калфак из рук». Социально-этическая проблематика в произведении. Изображение человека на чужой земле. Авторские ремарки. Образы, символы. Творчество поэта Фаннура Сафина. Изучение стихотворения «Туган җиремә»/ «Родной земле». Лирические произведения о родине, родной природе как выражение поэтического восприятия окружающего мира и осмысление собственного мироощущения, настроения. Творчество М. Галиева. Фрагментарное ознакомление с повестью «Нигез»/ «Родной очаг». Отражение в повести трудностей военного времени. Нравственная стойкость, чувство собственного достоинства, свойственные героям. Образное мышление автора. Проектная работа «Моя малая Родина»

**6.Яхшылык җиңә.Добро побеждает.**

Ф.Хөснинең тормыш юлы һәм иҗаты. “Сөйләнмәгән хикәя” хикәясендә” баланың сугыш чоры вакыйгаларын аңлавы. Р.Хафизова иҗаты. “Әти кайткан көн” хикәясендә сугыш чоры балаларының психологиясе. Ф.Яруллин иҗаты. “Ак төнбоек” хикәясендә дуслык проблемасының яктыртылуы, кешенең үз кыланышларына җаваплы булу темасының бирелеше. Р.Корбан иҗаты.”Ярдәм итик” шигырендә табигать һәм кешенең үзара мөнәсәсбәтләре. Р.Галиуллинның “Биш икеле” хикәясендә бала психологиясенең үзенчәлекле бирелеше
Жизнь и творчество Ф. Хусни Осмысление ребёнком событий войны в рассказе «Сөйләнмәгән хикәя»/ «Нерассказанная история». Жизнь и творчество Р. Хафизовой. Психология детей военных лет в рассказе «Әти кайткан көн»/ «В день возвращения отца» Р.Хафизовой. Творчество Ф.Яруллина. Своеобразное раскрытие проблем дружбы и ответственности человека за свои поступки в рассказе «Ак төнбоек» / «Белый лотос» Ф.Яруллина. Творчество Р.Корбана. Проблема взаимотношений человека и природы в стихотворении «Ярдәм итик» / «Давайте, поможем». Своеобразие изображения детской психологии в рассказе «Биш «икеле»/ «Пять «двоек» Р. Галиуллина. Раскрытие правственных проблем в рассказе «Табыш»/ «Находка» А.Ахметгалиевой.

**7. Табигатькә табиб кирәк.Природе нужен врач.**

М.Әгъләмов “Каеннар булсаң иде”,”Учак урыннары” әсәрләре белән танышу. М.Әгъләмов иҗатында тарихи истәлекләр проблемасының күтәрелеше, күпкырлы жанр формалары , стиль үзенчәлекләре.З. Мансуровның “ Балык кычкыруы” һәм Х. Ибраһимовның “ “Карач” хикәясендә Кеше һәм табигатьнең үзара мөнәсәбәтләре проблемасы. 7 нче сыйныфта үткәннәрне кабатлау һәм йомгаклау. М.Аглямов. «Каеннар булсаң иде» / «Как березы», «Учак урыннары» / «Места костров». Проблема «исторической памяти». Многообразие жанровых форм, стилевых черт в творчестве М.Аглямова. Проблемы взаимоотношения человека и природы в стихотворении «Балык кычкыруы»/ «Крик рыбы» З. Мансурова и в рассказе «Карач»/ «Ворон» Х. Ибрагима Повторение и обобщение изученного в 7 классе. Повторение. Тест

**8 класс**

**Тарих китабында безнең өчен бик күп хәтирәләр саклана/Память о прошлом.**

Предания «Сихерче кыз»/ «Колдунья» (Татарское народное предание) «Гали тугае»/ «Пойма имени Гали» (Татарское народное предание) «Моргана» (Средневековое европейское предание) и др. Легенда «Зөһрә кыз»/ «Девушка Зухра» (татарская легенда).

Тест

Фольклор жанрлары буларак риваятьләр, аның ничек барлыкка килүе. Риваять төрләре.

**Тарихи риваятьләр.** *Татар халыкының “Сихерче кыз” риваяте.* Әсәрдә Казан образының бирелеше, тарихы. Әлеге риваятькә хас әкияти алымнар *(1 сәгать).*

*Топонимик риваятьләр.* Татар халкының “Гали тугае” риваяте. Урта гасыр Европа халкының “Моргана”риваяте. *Шәһәр, авыл, тау һәм елга атамаларының килеп чыгышы (2 сәгать).*

*Легендалар. Аның төрләре. Легенданың риваятьтән аермалы яклары.*

**Татар халкының «Зөһрә кыз» легендасы.** Легендада Зөһрә образының бирелеше. Әсәрдә хыял мотивлары, аның кеше язмышын ачудагы роле. Әсәрдә гаиләдәге мөнәсәбәтләрнең бирелеше *(1 сәгать).*

Музыка уен кораллары, аларның халык тормышындагы роле *(1 сәгать).*

**I. Без тарихта эзлебез/ Следы в истории.**

Путевые заметки. Ознакомление учащихся с содержанием рисале «Ибн Фадланның 921-922 елларда Болгар дәүләтенә сәфәре вакытында язылган сәяхәтнамәсе» / «Повествование о путешествии Ахмеда Ибн Фадлана, написанное во время поездки в 921-922 годах в Булгарское государство»).

Жизнь и творчество Ф. Карими. Фрагментарное ознакомление с путевыми заметками «Аурупа сәяхәтнамәсе» / «Путешествие в Европу».

Творчество Г. Тукая. Воспевание родной земли в стихотворении «Пар ат» / «Пара лошадей». Сказочное воссоздание поездки в Казань. Лексические и фонетические средства художественной речи.

Сочинение на тему «Минем яраткан шагыйрем»/ «Мой любимый поэт».

Творческое наследие художника и скульптора Б. Урманче. «Триптих». Творчество Н. Назми. Чтение отрывка из повести «Агыйделдә – ак пароход» / «Белый пароход на реке Белой».

Повторение. Тест.

**Тарихи ядкарьләр буларак сәяхәтнамә һәм елъязма жанрлары. Ибне Фадлан** – Х гасырның беренче яртысында яшәгән гарәп сәяхәтчесе. Ибн Фадланның 921 – 922 нче елларда Болгар дәүләтенә сәфәре вакытында язылган сәяхәтнамәсе. Болгар дәүләтенең ил тарихындагы роле. Ил башлыгы Алмыш хан *(1 сәгать).*

**Фатих Кәрими.** Әдип һәм журналист тормышы һәм иҗат юлы. Аның Европа илләренә сәяхәте, бу сәяхәтнең максаты. «Аурупа сәяхәтнамәсе» әсәреннән өзек. Европа илләрендәге культура учаклары, Петербург китапханәсе турында мәгълүмат. «Аурупа сәяхәтнамәсе»нең әдәби роле *(1 сәгать).*

**Миргазиян Юныс**. Язучының тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Татар әдәбиятында диңгезчелек (маринистика) жанрына нигез салуы. Язучының “Су” хикәясе *(1 сәгать).*

*Әдәбият теориясе. Тарихи роман турында төшенчә (1 сәгать).*

Тарихи һәйкәл буларак **Казан Кремле**, аның төзелү тарихы. Кремльнең бүгенге торышы.

**Габдулла Тукай.** Язучының 1895 нче елда Җаек (Уральск) шәһәренә китүе. Анда Тукайның җәмәгать эшлеклесе, журналист, тәрҗемәче һәм шагыйрь буларак формалашуы. 1907 нче елда кире Казанга кайтуы. Шагыйрь иҗатының Казан чоры. Казанда аралашкан дуслары, балалар әдәбиятына һәм халык әдәбиятын өйрәнүгә керткән өлеше, театр эшчәнлегенә игътибары, сәяхәтләре, иҗтимагый эшчәнлеге. “Әл-ислах” газетасындагы эшчәнлеге. Габдулла Тукайның “Пар ат” шигыре. Аның язылу тарихы. “Пар ат” шигыренең лирик герое, аның кичерешләре, өметләре. Пар ат образының символикасы. Табигать, кучер образларының бирелеше, мәгънәләре *(2 сәгать).*

**Бакый Урманченың** “Пар ат” шигыренә иллюстрациясе. Картинада Габдулла Тукай шигырендә сурәтләнгән вакыйганың бирелеше.

**Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе. Премиянең беренче лауреатлары.**

Күренекле рәссам, сынчы **Бакый Урманченың** (1897 – 1990) тормышы. Ул тудырган скульптур портретлар, картиналар *(1 сәгать).*

**Нәҗар Нәҗми.** Шагыйрьнең тормыш һәм иҗат юлы. Аның Тукай шәкерте булуы, аның идеяләрен үстерүе. Н.Нәҗми иҗат иткән әсәрләрдә Тукай образының бирелеше, мәгънәсе. Шагыйрьнең «Татар теле» әсәрендә Тукай традицияләрен дәвам итүе. Н.Нәҗминең Бөек Болгарга сәфәре турындагы “Агыйделдә ак пароход” әсәреннән өзек. Әсәрдә сурәтләнгән “түгәрәк өстәл”, анда катнашкан язучылар. Әсәрнең әдәби мәгънәсе, кыйммәте *(1 сәгать).*

## II. Онытылмас еллар/ Незабываемые годы.

Жизнь и творчество Ф. Карима. Изучение произведений поэта «Ант»/ «Клятва», «Кыңгыраулы яшел гармун» / «Зеленая гармонь с колокольчиком». Патриотизм в поэзии периода Великой Отечественной войны. Картины природы, их роль в усилении психологизма.

Творчество Т. Миңнуллина. Образ поэта М.Джалиля в драме «Моңлы бер җыр» / «У совести вариантов нет» (отрывок). Память о М.Джалиле. Памятник поэту в Казани и барельеф его соратникам.

Чтение писем военных лет. Военная тематика в литературе разных народов.

Творчество киргизского писателя Ч. Айтматова. Система образов, проблема смысла жизни человека в повести «Анам кыры»/ «Материнское поле».

**Гариф Ахунов.** “Замандашлар портреты” әсәреннән өзек. Язучының әсәрдә рәссам Виктор Куделькинның иҗатын яктыртуы, аның картиналары турында уйланулары. Рәссам иҗатында М.Җәлил образы, аның бирелеше, иҗатчының халык язмышының кискен дәверләрен полотнода сурәтләве. В.Куделькинның “Билгесез биеклектә” картинасы, Бөек Ватан сугышы *(1 сәгать).*

**Сугыш турындагы җырлар.** Роберт Әхмәтҗановның “Озатып вокзаллар каршында…” (“Солдатлар”) шигыре. Сугышка баласын озаткан Ана образы. Татар халкының “Герман көе” җыры. Музыка сәнгатенең матур әдәбият белән тыгыз бәйләнештә булуы һәм бер-берсенә йогынтысы *(1 сәгать).*

**Фатих Кәримнең** тормышы, иҗаты. Аның иҗатында сугыш темасы, образларның бирелеше. Шагыйрьнең “Ант” шигыре, «азатлык» һәм «явызлык» проблемалары. “Кыңгыраулы яшел гармун” поэмасы, андагы образлар системасы. Гармун һәм җыр образының роле. Әлеге лирик әсәрләрдә сугыш проблемасының бирелеше *(3 сәгать).*

**Туфан Миңнуллин**. Күренекле драматург, язучы, публицист һәм җәмәгать эшлеклесенең тормышы һәм иҗаты. “Моңлы бер җыр” драмасы. Әсәрдә М.Җәлил образының бирелеше, аның тоткынлыктагы тормышы. Драмада фәлсәфи мотивлар, фантастик алымнарның роле. Т.Миңнуллинның “Моңлы бер җыр” публицистик драмасы турында белешмә *(2 сәгать).*

**Казанда Муса Җәлил һәйкәле һәм җәлилчеләргә куелган барельефлар.**

**Марсель Сәлимҗанов**. Режиссёрның тормышы, иҗаты. Аның татар профессиональ театрының, милли драматургиянең үсешенә керткән өлеше.

**Ринат Таҗетдинов.** Халык артистының тормышы һәм иҗаты, ул тудырган онытылмас образлар *(1 сәгать).*

**Фронт хатлары**, аның халык тормышындагы роле. Муса Җәлилнең кызы Чулпанга язган хаты, Фәтих Кәрим хатлары. Татар әдәбиятында эпистоляр жанр.

*Әдәбият теориясе. Эпистоляр жанр турында төшенчә (1 сәгать).*

**Мостай Кәрим.** Шагыйрь һәм язучының тормышы, иҗаты. “Билгесез солдат” шигыре. Шигырьдә билгесез солдат образы. Лирик геройның кичереше, шәхесләр язмышы *(1 сәгать).*

**Чыңгыз Айтматов.** Әдип турында белешмә. Аның “Анам кыры” әсәре. Әсәрдә Тулганай, Җир-ана образлары. Җыелма Җир-ана образына салынган мәгънә. Авторның сугыш турындагы уйланулары. «Анам кыры» повесте турында белешмә *(1 сәгать).*

**Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау** *(1 сәгать).*

**III. Әтинең зур бүреге иртә киелде/ Рано повзрослели.**

Творчество К. Булатовой. Изображение судьеб детей военных лет в стихотворении «Башым иям»/ «Преклоняю голову» К. Булатовой.

Изображение памяти военных лет в стихотворении «Җиңү көне» / «День победы» Н. Ахмадиева.

**Клара Булатова.** Шагыйрә турында белешмә. “Башым иям” шигыре, сугыш афәтенең шагыйрәнең балачагына тәэсире, хатирәләрендә калдырган эзе *(1 сәгать).*

**Нур Әхмәдиев.** Язучы иҗаты турында белешмә. “Җиңү көне” шигыре. “Минем туган көнем” хикәясе *(2 сәгать).*

**Факил Сафин.** Язучының тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Тулганай” әсәреннән өзекләр. Тулганай образы, аның әсәрдәге башка образларны ачудагы әһәмияте. Әсәрдә кешелеклек, шәфкатьлелек проблемалары *(2 сәгать).*

**Разил Вәлиев.** Тормышы һәм иҗади эшчәнлеге. “Ватаным” шигыре. Сугыш, аның гади халык, балалар җилкәсенә алып килгән авырлыгы *(1 сәгать).*

**Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау** *(1 сәгать).*

**IV. Ана-изге, Ана-бөек, ана-дан! Аңлар өчен йөрәгенең олылыгын, туу кирәк кайчак безгә яңадан!/ Образ матерей в литературе.**

Жизнь и творчество Ш. Камала. Анализ новеллы «Буранда»/ «В метель». Эмоциональная насыщенность текста: средства и приемы. Особенности композиции.
Жизнь и творчество С. Хакима. Сокровенные пожелания в стихотворении «Җырларымда телим…»/ «Желаю в песнях…». Лиризм и социально-философское осмысление национальных историко-культурных традиций в творчестве поэтов старшего поколения. Стихотворения «Әнкәй» / «Мамочка» Р. Миннуллина, «Су буеннан әнкәй кайтып килә»/«Мама возвращается с реки» М. Галиева.
Творчество Ф. Садриева. Нравственная проблематика: отрывок из романа «Таң җиле» / «Утренний ветер». Образ Нуриасмы.

**Аңлар өчен йөрәгенең олылыгын,**
**Туу кирәк кайчак безгә яңадан!**

**Шәриф Камал.** Әдипнең тормышы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат. “Буранда” новелласы. Төп геройның язмышы. Аның эчке дөньясы, күңел халәте. Психологик алымнар. Әсәрдә Ана образына хас сыйфатлар.

*Әдәбият теориясе. Әдәби деталь. Матур әдәбиятта психологизм. Новелла турында төшенчә (2 сәгать).*

**Ибраһим Салахов.** Язучының тормышы һәм иҗаты. Репрессияләнгән әдипләр язмышы. “Халык дошманы” төшенчәсе. “Ана тавышы” хикәясе (“Колыма хикәяләре” циклыннан). Ялгыз ананың аяныч язмышы, кичерешләре. Автор әйтергә теләгән фикер *(2 сәгать).*

**Сибгат Хәким.** Шагыйрьнең тормыш юлы**,** иҗаты турында мәгълүмат. Иҗатында яктырткан темалар. “Әнкәй” шигырендә Ана образына хас сыйфатлар. Лирик геройның хис-кичерешләр бирелеше. Сагыну хисе. “Җырларымда телим” шигыре. Шигырьнең эчтәлеге, поэтик яңгырашы, сурәтләү чаралары. Шигырьдә күтәрелгән проблемалар *(2 сәгать).*

**Роберт Миңнуллин.** Әдипнең тормыш юлы, иҗаты. Әдәбиятка булган мәхәббәте. Иҗатында яктыртылган темалар. “Әнкәй” шигыре. Ана образының бирелеше. Лирик геройның уйлары, кичерешләре *(1 сәгать).*

**Марсель Галиев.** Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты турында мәгълүмат. “Су буеннан әнкәй кайтып килә” шигыре. Шигырьдә ана образы. Лирик геройның туган ягы турында хис-кичерешләре. “Кабатланмас әкият” шигыре. Хыялда туган авыл күренеше. Балачакка кайту теләге, лирик геройның хис-кичерешләре. Ана образының бирелеше **Луиза Батыр-Болгари.** Композиторның тормыш юлы, иҗаты *(2 сәгать).*

**Шәриф Хөсәенов.** Әдипнең тормыш юлы һәм иҗаты турында мәгълүмат. Беренче драмалары турында белешмә. “Әниемнең ак күлмәге” (“Әни килде”) драмасы. Драмада ана образының бирелеше. Ананың язмышы, балаларына булган мәхәббәте. Автор әйтергә теләгән фикер. Шәриф Хөсәеновның “Әниемнең ак күлмәге” (“Әни килде”) драмасы турында. Драманың татар әдәбиятында тоткан урыны. Ана образы турында мәгълүмат. Аналар һәм балалар проблемасы *(2 сәгать).*

**Фоат Садриев.** Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Таң җиле” романы. Романда бирелгән образларның язмышы, ана (Нуриәсма) образының бирелеше. Нәсимә белән Фәритнең үз-үзләрен тотышы, уллары Маратның авылда терелүе, сөйләшә башлавы, дуслар табуы. Авторның әйтергә теләгән фикере *(3 сәгать).*

**Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау** *(1 сәгать).*

**VI . Көлсәң – көл, еласаң – ела!/ Юмор.**
Жизнь и творчество Г. Камала. Конфликт в комедии Г. Камала «Банкрот». Просветительские идеи, комические средства.
Жизнь и творчество Г. Афзала. Особенности писательской карьеры в рассказе «Юл газабы» / «Страдания в пути».

**Беренче сатирик журналлар.** Беренче сатирик журналлар турында белешмә. Вакытлы матбугатны башлап җибәргән шәхесләр.

*Әдәбият теориясе. Сатира турында төшенчә (1 сәгать).*

**Галиәсгар Камал.** Әдипнең тормыш юлы, иҗаты, татар әдәбиятында тоткан урыны. **“Банкрот” сатирик комедиясе.** Сиражетдин Туктагаевның тормыш, көнкүреше, уйлаган хәйләсе. Тирә-юньдәге образларның үз-үзләрен тотышы. Галиәсгар Камалның “Банкрот” комедиясе турында белешмә. Әсәрнең сәхнә тарихы. Әдип тарафыннан күтәрелгән проблема.

*Әдәбият теориясе. Конфликт турында төшенчә. Сарказм. Проза әсәрләрендә сатира (2 сәгать).*

**Гамил Афзал.** Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында кыскача мәгълүмат. Юмор-сатира өлкәсендә тоткан урыны “Юл газабы” хикәясе. Хикәяләүче авторның язмышы турында белешмә. “Тәвәккәл әби” шигыре. Әбинең аянычлы язмышы, эш-гамәлләре. Шигырьнең эчтәлеге, поэтик яңгырашы. Автор идеясе. Сурәтләү чаралары. Шигырьдә күтәрелгән проблемалар.

*Әдәбият теориясе. Сатирик шигырь. Ирония турында төшенчә (2 сәгать).*

**Зәки Нури.** “Пародия”. Пародиянең язылу стиле. Пародиягә салынган эчтәлек. Төрле шәхесләргә багышланган эпиграммалар. Эпиграммаларда сарказм.

*Әдәбият теориясе. Пародия турында төшенчә. Эпиграмма (1 сәгать).*

**Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау** *(1 сәгать).*

**VII. Даһи гомере- халык хәтерендә!/ Великие дети народа.**

Жизнь и творчество Р. Хариса. Величие души человека, философский подтекст стихотворения «Ике гөл»/ «Два цветка». Творчество актрисы Г. Кайбицкой. Ее жизненный путь. Образа актрисы в документальной повести «Артистка» / «Актриса» Ф. Аглии. Творчество Р. Батуллы. Своеобразие образа легендарного танцора Рудольфа Нуриева в произведении «Бию» / «Танец» (отрывок).

**Ренат Харис.** Шагыйрьнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Гармунчы” поэмасы. Поэманың эчтәлеге. Лирик геройның бирелеше. Поэмада кулланылган сурәтләү чаралары. Гармуннан чыккан көйләрнең сурәтләнеше. “Ике гөл” шигыре. Шигырьнең идеясе, төзелеше. Шигырьгә салынган мәгънә. Автор әйтергә теләгән фикер *(2 сәгать).*

**Зөлфәт.** Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Юмор-сатира өлкәсендә ирешкән уңышлары. “Шигырем – ачык!” ,“Шундый чагы әле җанымның” шигырьләре. Аларда лирик геройның хис-кичерешләре. Әдип шигыренә хас үзенчәлекләр.

*Әдәбият теориясе. Документаль повесть жанры (2 сәгать).*

**Галия Кайбицкая.** Актрисаның тормыш юлы турында белешмә. Татар музыка сәнгатен һәм операсын үстерүгә керткән өлеше *(1 сәгать).*

**Рабит Батулла.** Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. Төрле жанрларда иҗат итүе. “Бию” кыйссасы. Рудик белән бәйле, госпитальдә булган көлкеле вакыйганың әдәби гәүдәләнеше. Яшь талантның беренче уңышы *(2 сәгать).*

**Бүлектә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау** *(1 сәгать).*

**VIII. Табигатьнең дә җаны, рухы бар/ Природа одушевленная.**

Жизнь и творчество А. Халима. Изображение суровых военных лет и судеб детей в повести «Өч аяклы ат» / «Трёхногая кобыла».
Творчество К. Каримова. Реалистическая основа истории в рассказе «Тимергали бабай хикәяте» /«Рассказ Тимергали бабай».

**Айдар Хәлим.** Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Өч аяклы ат” повесте. Әсәрнең эчтәлеге. Кәбирнең язмышы, атка мөнәсәбәте. Аның тирәсендә булган башка геройларның үз-үзләрен тотышы. Ат образының бирелеше *(3 сәгать).*

**Гарәфи Хәсәнов.** Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Беренче күк күкрәү” хикәясе. Язгы табигать күренешенең сурәтләнеше. Геройның язгы табигать турында уйлары, хис-кичерешләре. Беренче күк күкрәү мизгелләренең тасвирланышы *(2 сәгать).*

**Камил Кәримов.** Әдипнең тормыш юлы, иҗаты турында белешмә. “Тимергали бабай хикәяте” хикәясе. Хикәянең эчтәлеге. Авторның Сабантуй бәйрәмен тасвирлау үзенчәлеге. Заманга хас булган атрибутларның бирелеше (кулъяулык бирү, аулак өй күренеше һ.б.) *(1 сәгать).*

**“Ялкын” журналы.** Журналның тарихы. Журнал рубрикалары. Мәкаләләрнең эчтәлеге *(1 сәгать).*

**Ел дәвамында үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлау** *(1 сәгать)*

## 9 класс

**Сүз көче Сила слова.**

Дастаннар турында төшенчә бирү. “Идегәй” дастаныннан өзек.Кыскача эчтәлеге, күтәрелгән проблема, төп геройлар, сәнгать үзенчәлекләре.Әңгәмә өчен тема: геройлар: милли гомумкешелек сыйфатлары. Кол Галинең “Кыйссаи Йосыф” поэмасы- Болгар-татар әдәбиятының ( XII- XIII гасырның беренче яртысы ) язма истәлеге. Зирәклелеккә, матурлылыкка, кеше хисләренең куәтлегенә дан җырлау. Кабатлау.

Краткое содержание, проблематика, основные герои и художественные особенности дастана «Идегей» (в сокращении). Тема для обсуждения. Герои эпоса: национальные и общечеловеческие черты. Поэма Кул Гали «Кыйссаи Йосыф» / «Сказание о Йусуфе» — письменный памятник Булгаро-татарской литературы (XII — первая пол. XIII вв.) Воспевание мудрости, красоты, величия чувств человека.

**Урта гасыр татар әдәбиятында мәхәббәт сюжетлары Любовные сюжеты в средневековой татарской литературе**

Төрки- татар әдәбияты вәкилләре. Сәиф Сарай иҗаты. “Сөһәйл вә Гөлдерсен” дастаныннан өзек белән танышу.

Тюрко-татарская литература: основные представители. Творчество Саифа Сараи. Знакомство с отрывком из дастана “Сөһәйл вә Гөлдерсен”/ “Сухайль и Гульдурсун”

**Татар әдәбиятында хатын-кыз образлары. Женские образы в татарской литературе.**

Г.Кандалый “Сәхипҗамал” поэмасы, Р.Фәхретдин “Әсма , яки гамәл вә җаза” романыннан өзек, Г.Тукай“ Татар кызларына” шигыре . Ф.Әмирхан “Хәят” повесте, А.Гиләҗев “ Җомга көн кич белән”Р. Мингалим “Сап- сары көзләр”хикәясе. Әсәрләрдә идея-эстетик идеалның чагылышы. Кабатлау.Обзор: поэма Г. Кандалый «Сәхипҗәмалга» / «Сахибзямалу», роман Р. Фахрутдинова «Әсма, яки Гамәл вә җәза» / «Асма, или Деяния и наказание» (отрывок), стихотворение Г. Тукая «Татар кызларына»/ «Татарским девушкам», повесть Ф.Амирхана «Хәят» / «Хаят», А. Гилязева «Җомга көн, кич белән» / «В пятницу, вечером…», рассказ Р. Мингалима «Сап-сары көзләр» / «Золотая осень». Трансформация идейноэстетического идеала.

Татар әдәбиятыннан лирик башлангыч Лирическое начало в татарской литературе.

Татар шигърияте : пейзаж лирикасы: Р.Зәйдулла «Буран» шигыре. И.Иксанова « Тузганак». Гражданлык лирикасы: С.Әхмәтҗанова “Татар акылы”, “Сүнмәс балкыш” шигыре. Фәлсәфи лирика: М.Шабаев “ Корыган имән монологы” М.Мирза . Робагыйлар “Карыйм да бу дөнья ның дүрт ягына”. Мәхәббәт лирикасы: Ф” Җамалетдинова “ Ташлар”, “Кунак көткән көн”. Р.Әхмәтҗанов “ Сандугач керде күңелгә”.

Бүлекне кабатлау. Татарская поэзия: пейзажная лирика (Р.Зайдулла. «Буран» / «Буря», И.Иксанова. «Тузганак» / «Одуванчик»);  гражданская лирика (С. Ахметзянова. «Татар акылы» / «Татарская мудрость»); философская лирика (Ф.М. Шабаев. «Карт имән монологы»/ «Монолог старого дуба», М. Мирза. Робагыйлар. «Карыйм да бу дөньяның дүрт ягына… » /Рубаи. «Гляжу я на четыре стороны этого мира»); любовная лирика (Ф. Замалетдинова. «Ташлар» / «Камни», «Кунак көткән көн» / «День ожидания гостей», Р. Ахметзянов. «Сандугач керде күңелгә» / «Душа поет»).

**Театр элгечтән башлана «Театр начинается с вешалки».**

Татар драматургиясенә нигез салучыларның берсе-Г.Камалның тормыш юлы һәм иҗаты белән танышу.
Г.Камалның “ Беренче театр” комедиясендә төп конфликтлар. Мәгърифәтчелек идеяләре, комик чаралар.
С.Гыйззәтуллина –Волжскаяның сәхнә тормышы, иҗаты.
Х.Мөдәррисованың тормыш юлы һәм иҗаты .Сәнгать кешесе тормышының “Бәйге хакы” повестында чагылыш табуы. Кабатлау.
Жизнь и торчество Г. Камала — одного из основоположников татарской реалистической драматургии.
Основные конфликты в комедии Г. Камала «Беренче театр» /«Первый театр». Просветительские идеи, комические средства.
Сценическое творчество С.Гиззатуллины-Волжской.
Жизнь и творчество Х. Мударрисовой. Жизнь человека искусства в повести «Бәйге хакы» / «Цена счастья».

**Укытучы - горур яңгырый! Учитель – звучит гордо!**

М.Мәһдиев иҗаты.”Фронтовиклар” романыннан өзек өйрәнү. Лирик чигенүләр. Образлар системасы.
Казан педагогия коллияте турында.
Р. Гаташның остазлар һәм укытучыларга багышланган “ Укытучы”, Л.Шагыйрьҗанның “ Укытучы” шигыре, В. Нуриевның “Инша “ хикәясе белән танышу.
Материалны кабатлау. Тест. Проект эше “ Минем беренче укытучым”.
Творчество М. Магдеева. Фрагментарное изучение романа «Фронтовиклар» / «Фронтовики». Лиризм и орнаментализм в татарской прозе. Лирические отступления. Система образов.
О педколледже в Казани.
Ознакомление со стихотворениями о наставниках и учителях «Укытучы» / «Учитель» Р. Гаташа, «Укытучым» / «Мой учитель» Л. Шагирзяна, и с рассказом «Инша» / «Сочинение» В. Нуруллина.

Проектная работа «Мой первый учитель».

**Һөнәрләр күп алар Изобилие профессий.**

Х.Сарьян «Әткәм һөнәре». Авторның төп геройны тасвирлау үзенчәлекләре, автор позициясе.
Г.Ахуновның тормыш юлы һәм иҗаты. “Хәзинә” романыннан өзек. Романның төп эчтәлеге. Нефть һәм нефтьчеләр темасының чынбарлыкта сүрәтләнеше.
И.Юзеевның тормыш юлы һәм иҗаты. “Казан каласы- таш кала” өзеген өйрәнү.Шәһәртөзүчеләр һөнәренә әзерләү үзенчәлекләре.
С.Гәрәеваның тормыш юлы. “Сварчик егет” шигырен өйрәнү. Шигырьнең идея-эстетик мәгънәсе.
9 нчы сыйныфта үткәннәрне кабатлау һәм йомгаклау.

Изучение отрывка из повести Х. Сарьяна «Әткәм һөнәре» /«Отцовская профессия». Авторская позиция и особенность изображения главного героя.
Жизнь и творчество Г. Ахунова. Фрагментарное изучение романа «Хәзинә» /«Клад». Основное содержание романа. Реалистичное изображение темы нефти и нефтяников.
Жизнь и творчество И. Юзеева. Фрагментарное изучение поэмы «Таныш моңнар» / «Знакомые напевы». Образы молодого поколения, совместимость выбора профессии с идеалами молодой девушки.
Жизнь и творчество Х. Камалова. Изучение рассказа «Очучы» / «Летчик». Авторская позиция.
Жизнь и творчество М. Маликовой. Изучение отрывка из повести «Казан каласы – таш кала» / «Казань – город белокаменный». Особенности профессиональной подготовки градостроителей.
Биография С. Гараевой. Изучение ее стихотворения «Сварщик». Идейно-эстетический смысл произведения.
Повторение и обобщение изученного в 9 классе.

**КАЛЕНДАРЬ-ТЕМАТИК ПЛАН**

**5 класс**

| Дә-рес № | Дәрес темасы | Сәгать саны | Укучыларның эшчәнлек төрләре | Үткәрү вакыты | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | План | Факт |
| 1 | Татар халык әкиятләре. «Өч кыз»<br>Татарская народная сказка « Три дочери» | 1 | «Халык авыз иҗаты» схемасы белән эш, дәреслектә, эш дәфтәрендә биремнәр, рус халык авыз иҗаты белән чагыштырып, мисаллар китерү. Әкияттәге уңай һәм тискәре образларны чагыштыру. | | |
| 2 | Татар халык әкияте «Өч кыз»<br>Татарская народная сказка « Три дочери» | 1 | «Әкиятләр» схемасы белән эш, дәреслек, эш дәфтәрендә биремнәр эшләү, чылбыр буенча уку, чылбыр буенча сөйләү, җөмләләр төзү. Әкиятне сәхнәләштерү. | | |
| 3 | “Куркак юлдаш” татар халык әкияте<br>Татарская народная сказка «Пугливый путник» | 1 | Әкиятне укып чыгу һәм терәк сораулар буенча анализлау, гомумиләштереп, нәтиҗәләр чыгару. | | |
| 4 | Каюм Насыйри. Тормыш юлы<br>К Насыри.Биография | 1 | 2 бүлекне укып чыгу һәм терәк сораулар буенча анализлау, гомумиләштереп, нәтиҗәләр чыгару. | | |
| 5 | «Патша белән карт» әкияте<br>«Царь и старик» | 1 | 3 бүлекне укып чыгу һәм терәк сораулар буенча анализлау, гомумиләштереп, нәтиҗәләр чыгару. Халыкның бер вәкиле булган тапкыр карт образы турында сөйләшү. | | |
| 6 | Габдулла Тукай. «Су анасы» әкият-поэма<br>Габдулла Тукай «Водяная» сказка-поэма | 1 | Әкияттәге уңай һәм тискәре образларны табу, аларга хас сыйфатларны билгели белү. Әдип турында мәгълүмат бирү. | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 7 | Борын-борын заманда...<br>Древние времена | 1 | Бәйләнешле сөйләм  телен үстерү, белемнәрне тикшерү. | | |
| 8 | «Әкият» курчак театры<br>«Сказка» кукольный театр | 1 | Бәйләнешле сөйләмтелен үстерү, белемнәрне тикшерү. | | |
| 9 | Адлер Тимергалин “Сәер планета”<br>Адлер Тимергалин «Странная планета» | 1 | Әңгәмә, сәнгатьле уку. Бирелгән билгеләмәләргә нигезләнеп, нәтиҗә ясау. Үз фикереңне әйтә белергә өйрәнү. | | |
| 10 | Рудольф Эрих Распе «Сигез аяклы куян». Белемгә омтылу. «Мөхәммәдия» мәдрәсә<br>Рудольф Эрих Распе «Зайчик с восьми ногами», Медресе «Мухаммадия» | 1 | Әкиятне уку, дәреслек, эш дәфтәрендә биремнәр эшләү, әкият-поэмада әкияткә хас сыйфатларны табу. | | |
| 11 | Мөхәммәдия» мәдрәсәсе<br>Медресе «Мухаммадия» | 1 | Рәсемне аңлау, төп детальләргә игътибар итеп, аның эчтәлеген сөйләтү, нәтиҗә ясау. | | |
| 12 | Казанның Татар укытучылар мәктәбе<br>Казанская татарская учительская школа | 1 | Әкият-пьесаны сәнгатьле итеп уку, аңлаганны сораулар ярдәмендә тикшерү, анализлау. | | |
| 13 | Гаяз Исхакый турында белешмә<br>Биография Гаяза Исхаки | 1 | Яңа материал белән танышу, укытучының кереш сүзе, укылган текст буенча фикер алышу. | | |
| 14 | Дәрдемәнд . Дәрдемәнднең «Кил, өйрән...» шигыре.<br>Дардманд. Стихотворение “Иди ,учи”. | 1 | Хикәяне уку, сүзләрне аңлату, сораулар буенча төп фикерне табу, нәтиҗә ясау, шигырьне тәрҗемә белән уку. | | |
| 15 | Габдулла Тукайның «Исемдә калганнар» әсәре<br>Габдулла Тукай “Воспоминания” | 1 | Хикәяне уку, сүзләрне аңлату, сораулар буенча төп фикерне табу, нәтиҗә ясау. | | |
| 16 | Габдулла Тукайның “Исемдә калганнар” әсәре<br>Габдулла Тукай “Воспоминания” | 1 | Хикәяне уку, сүзләрне аңлату, сораулар буенча төп фикерне табу, нәтиҗә ясау. | | |
| 17 | “Салават күпере” журналы<br>Журнал «Радуга» | 1 | Сайлап алып уку, укыганны анализлый белү, үз фикереңне тексттан дәлилләр табып исбатларга өйрәнү, белемнәрне тикшерү. “Салават күпере” журналы турында сөйләшү, диалогик сөйләм | | |
| 18 | Гадел Кутуйның тормышы һәм иҗаты<br>“Рөстәм маҗаралары” әсәре<br>Жизнь и творчество Аделя Кутуя "Приключения Рустама" | 1 | Укучылар үзләре уйлап язган яки башка авторларныкы бул-ган, тәрҗемә иткән әкият һәм фантастик әсәр-не китапчык итеп, рәсемнәр б-н бизәп, сый-ныфташларына тәкъдим итәләр. | | |
| 19 | Муса Җәлилнең тормышы һәм иҗаты<br>“Сагыну” шигыре<br>Жизнь и творчество Мусы Джалиля Стихотворение” Тоска" | 1 | Уку, эчтәлеге буенча фикер алышу, мәкальләр уку, рәсемнәр күзәтү. Төрле биремнәр эшләү. | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 20 | Нәҗип Җиһановның иҗаты. «Алтынчәч» либреттосы<br>Творчество Назиба Жиганова. " Алтынчәч " либретто | 1 | Китаптагы текст белән танышу, уку, укытучының истәлекләр белән таныштыруы. Опера, либретто төшенчәләре аңлату | | |
| 21 | Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры<br>Татарский государственный академический театр оперы и балета им. Мусы Джалиля | 1 | Театр, балет, опера сәнгате белән әдәбиятны бәйләп өйрәнү. Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт<br>академия опера һәм балет театры турында дәреслектәге<br>белешмә һәм өстәмә материаллар аша танышу. | | |
| 22 | Фатих Кәримнең тормыш юлы һәм иҗаты. «Кыр казы» шигыре. Ф. Кәрим "Сөйләр сүзләр бик күп алар" шигыре<br>Жизнь и творчество Фатиха Карима. Стихотворение «Полевой гусь". Стихотворение Ф. Карима "Они говорят много слов" | 1 | Фатих Кәримнең тормыш юлы һәм иҗаты турында<br>белемнәрне үзләштерү. Шигырьләрне тәрҗемә белән уку. Аларда Туган илне саклау, ярату хисләренең<br>салынган булуын аңлау. | | |
| 23 | Ш.Галиевның тормыш юлы һәм иҗаты "Аталы-уллы солдатлар" әсәре<br>Биография и творчество Ш. Галиева. Произведение "Аталы - уллы солдатлар" | 1 | Язучы иҗатына күзәтү ясау,әсәрен укып, ярдәмче<br>сорауларга нигезләнеп, аңа бәя бирү. | | |
| 24 | Нәби Дәүлинең тормышы, иҗаты. «Бәхет кайда була?» шигыре<br>Жизнь и творчество Наби Даули. Стихотворение "Где счастье? | 1 | Шагыйрь Нәби Дәүлинең тормыш юлы һәм иҗатытурында белемнәрне үзләштерү. Нәби Дәүлинең«Бәхет кайда була?»шигырендә бәхет эзләү һәмтабу кебек фәлсәфи мәсьәләнең чишелешен күзәтү. Лирик герой өченбәхетнең үзе яшәгән җирдә булуын аңлау. Теоретик төшенчә белән танышу | | |
| 25 | Фатих Хөснинең «Чыбыркы» хикәясенең сюжеты, геройлары.<br>Рассказ Фатиха Хусни «Кнут» сюжет, герои. | 1 | Хикәядә малайның үз эшләре өчен җавап бирүен күрү. Авторның бала психологиясен ачу үзенчәлеген үзләштерү. Теоретик төшенчә белән танышу (Сюжет, сюжет элементлары:экспозиция,төенләнеш,вакыйгаларүстерелеше, кульминация,чишелеш). | | |
| 26 | Ф.Садриев "Көнбагыш чәчәге" хикәясе.<br>Рассказ Ф. Садриева "Подсолнух". | 1 | Укыганны гомумиләштерә,нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү. | | |
| 27 | Әнвәр Рәшитов "Кояшлы ил- бәхет иле" шигыре<br>Анвар Рашитов стихотворение "Солнечная страна - страна счастья" | 1 | Балаларда бәхетнең кадерен белеп яшәү хисләрентәрбияләү. | | |
| 28 | Мәгъсүм Хуҗинның «Туган көн» хикәясе<br>Рассказ «День Рождения " Магсума Хузина | 1 | Укучыларда эстетик зәвык тәрбияләү.Әсәрдәге вакыйгалар аша балаларда җаваплылыкхисләре тәрбияләү. Олыларга игътибарлы булырга өйрәнү.Кешеләрнең күңелен күтәрү - зур бәхет булуын ачыклау. | | |
| 29 | Равил Фәйзуллинның тормышы, иҗаты. «Табигать | 1 | Текст укыганда, кирәкле мәгълүматны аерып алу,системага салу. Сорауларга дөрес | | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | кочагында» шигыре<br>Жизнь и творчество Равиля Файзуллина. Стихотворение "В объятиях природы" | | җавап бирү. Шигырьдә табигатьне саклау, аны ярату хисләре өстенлек итүен ачыклау. | | |
| 30 | Мөдәррис Әгъләмовның тормыш юлы һәм ижаты. «Матурлык минем белән» шигыре<br>Жизнь и творчество Мударриса Аглямова. Стихотворение "Красота со мной" | 1 | Лексиканы сөйләм телендә куллану, сорауларга дөрес<br>җавап бирү. Матурлыкны табигатьтән эзләү мотивын аңлау. Табигатьнең кешеләргә мәрхәмәтле булуына, аны сакларга кирәклегенә төшенү. | | |
| 31 | Рәссам Иван Иванович Шишкин иҗаты .” Шишкин картиналарында туган як табигате ”<br>Творчество художника Ивана Ивановича Шишкина. "Шишкин в картинах «Природа родного края ” | 1 | Парларда үзәйтү. Аның Татарстан белән бәйле язмышын өйрәнү. Һәр ел фылының<br>булуын белү. | | |
